**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Нижнеалькеевского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Түбән Әлки авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422881, РТ, с. Нижнее Алькеево
ул. Советская, д. 55
8 (84346) 77-2-15

Адресы: 422881, РТ, Тубэн Элки авылы, Совет ур., 55
факс: 8 (84346) 77-2-15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 13 апреле** **19№**

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 25 гыйнварындагы « Түбән Әлки авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Нигезләмәне раслау хакында» 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Конституциясе, 1996 елдагы «Оборона турында» 61-ФЗ номерлы, 1997 елдагы «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизацияләү турында» 31-ФЗ номерлы, 1998 елдагы «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 53-ФЗ номерлы, 2003 елдагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмәне раслау хакында» 719 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 6 февралендәге «Хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 103 номерлы карары, Җирлек Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. « Түбән Әлки авыл җирлеге» территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта «(3 айдан артык вакытка)» сүзләреннән соң «шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча теркәлгәннәре дә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
« Түбән Әлки авыл җирлеге»
Башкарма комитет җитәкчесе: М.Р. Галиуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕАЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЬКЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА